
ISSN 0868-4545
5/92
Май
Салават күпере
Бөтендөнья татар конгрессы
Казан 1992



Чарасын тапкан

Мәзәк

Бер нәни кыз әнисенә әйтә икән:
— Әни! Сөт чиләгенә тычкан төшкән!
— Төшсә ни хәл итәсең инде, кызым? Алып ташлагансыңдыр бит? — дигән әнисе.
— Юк, тотарга курыктым. Тычканны тотарга дип песине дә чиләккә ташладым! — дигән нәни кыз.

Рәссам Фәрит ЯКУПОВ

Әкият башы

И-и, карагыз, мич астыннан ни аулап
Килеп чыкты әнә мәче мияулап?..
Бу тик әкиятнең баласы,
Мич башында ята бабасы,
Коймак изә әбисе,
Таба майлый анасы.
Табагачтыр, коймактыр,
Сөйләгәнне тыңлап тор.
Иләктер дә чиләктер,
Колагыннан эләктер.

Читәнме, бүзме?



Шаяру

Сиздермичә генә арттан килеп, күзне каплыйлар да:

— Читәнме, бүзме? — дип сорыйлар.

Теге бала:

— Бүз,— дисә,

— Бер чеметкәнгә түз,— дип чеметәләр.

— Читән,— дисә,

— Бер чеметәм дә китәм,— дип, чеметеп китәләр.




Эт кычкыра, мин өрәм

Чуалтмыш

Ыргадан, мыргадан,
Төшеп калдым арбадан,
Эт кычкыра, мин өрәм,
Ат йөгерә, мин чабам,
Тәртә өзелде, бау сынды,
Аптырадым бит тәмам.

© «Салават күпере», 1992 ел



ИКЕНЧЕ ДӘРЕС

Түбәндәгеләрне исеңдә тот:

а) Уен башланыр алдыннан һәр як үз фигураларын 1 нче һәм 2 нче рәткә тезә.

б) Уен башланганда Ферзь һәрвакыт үз төсендәге кырга (шакмакка) куела (ак Ферзь — ак кырга, кара Ферзь — кара кырга).

в) Ферзь белән янәшә Корольне куялар. Ак Король уен башында кара кырга, кара Король — ак кырга куела.


г) Уенчыларның берсе дә алмаганда, уен ничья булып тәмамлана.

д) Баштан алып азакка кадәр бара торган бер уен партия дип атала.

е) Һәр фигураның кыскартылган билгесе болай: Король — Кр, Ферзь — Ф, Ладья — Л, Фил (слон) — С, Ат (конь) — К. Пешканың билгесе куелмый.

ж) Фигураларның тактадагы торышын язу тәртибе: иң элек фигураның кыскартылган билгесе куела, ул билге белән янәшә фигура торган йорт-шакмакның билгесе языла. Мәсәлән: Кс4 (рәсемгә кара).

Дәресне Абрам ЛИВШИЦ алып бара.



КЫЗЫКЛЫ АРИФМЕТИКА

НИЧЕК БҮЛӘРГӘ?



● Ике әти кеше һәм ике угыл иртән өч йомырка ашый. Аларның һәрберсенә бер бөтен йомырка элэгэ. Ничек болай булырга мөмкин?

(Иртән өч кенә кеше ашый: бабай, аның улы һәм оныгы, ягъни ике әти һәм ике угыл).



● Кәрзиндә дүрт алма бар. Шуларны дүрт кешегә бүләргә кирәк. Бер алма кәрзиндә калырга тиеш.

(Бер кеше үзенә тиешле алманы кәрзине белән ала).

Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Нәкыйп КАШТАН

ТАТЛЫ ШАЛКАН

Хикәя



Урамда уйнап йөргәндә Фиркатьнең бик тә шалкан ашыйсы килеп китте. Ул Алсу апалар бакчасында үскән шалканнарны исенә төшерде дә шунда йөгерде. Анда Алсу апасы, авырткан аягын кичке кояш нурларында җылытып, оек бәйләп утыра иде. Янында мөлдерәмә сулы зәңгәр чиләкләре. Гүя алар коргаксыган түтәлләргә су сипкәнне көтәләр.

Апасы малайны шунда ук күреп алды:

— Фиркать үскәнем, хәлемне белергә килдең мәллә? — диде.

Малай оялып куйды.

— Алсу апа, шалканнарыгыз суга сусаган ич! — диде ул.

— Ай-һай, энем, үткен дә соң күзләрең...

— Су сибимме соң үзләренә?

— Сип әле, сип, энем! Корып-кибеп, суга сусап ятмасыннар.

Фиркать апасы янында торган чиләк-чүмечне алды да шалканнарга, кыярларга, суганнарга ашыга-ашыга су сибә башлады. Суны сибеп бетергәч, янә шалкан түтәлләренә күз салды. Көне буе кояш эссесендә әлсерәп, шиңеп беткән шалкан яфраклары күзгә күренеп тернәкләнеп, яшелләнеп киткән иде. Түтәл читендәгеләре сары түшләрен кояшка куеп, йолкып алып ашаганны көтәләр сыман тоелды.

Фиркатьнең авызыннан тәмле сулар килде. Ул:

Рәссам Алла АЙСИНА



— Апа, түтәлләреңә суны күп итеп сиптем... Шалканнар тагын да зуррак булып үсеп киттеләр,— диде.

Апасы елмаеп:

— Шулаймыни, энем. Алайса, үзеңә карап торган иң зур шалканнан авыз ит инде,— диде.

Фиркать, шатлыгын сиздермәскә тырышып, түтәл читендәге зур, сары түшле шалканның яшел яфракларын учлап, йолкып та алды. Йолкып алгач ни күрсен, тагын бер йомры гына шалкан ияреп чыккан. Малай, каушый төшеп, апасына карады. Ә апасы көлеп:

— Күрәсең, алар үзләренә су сипкән өчен сине яратып, парлап чыкканнардыр, энем. Тәмле итеп аша әле үзләрен,— диеп, малайның янына ук килеп, йомшак кулы белән аркасыннан сөйде.

Фиркать апасына рәхмәт әйтте дә, татлы шалканын ашыйашый, урамга, уйнарга чыгып чапты.



Борынгы бабаларыбыз

БОЛГАР ХАН

743—809 елларда тәхеттә Болгар исемле хан утыра.

Ул — моңа кадәр булган ханнар арасында иң кыю, иң куәтле вә батыр, зирәк һәм акыллы хан. Болгарлар аны шул кадәр яраталар һәм хөрмәт итәләр ки, башкалаларын да бу хан исеме белән йөртә башлыйлар.

Болгар хан Дунай буендагы кардәш болгарларга илчеләр җибәрә. Күзгә күренеп дөнья базарына әверелә башлаган мәркәзи Болгарга Киев Рәсәеннән, Табгачтан, Иран, Мисыр, Урта Азия



Рәссам Рушан ШӘМСЕТДИН

калаларыннан сәүдәгәрләр агыла. Сәүдәгәрләргә ияреп имамнар, табибләр, галимнәр, сәяхәтчеләр килә.

Болгар дәүләтенең даны еракларга барып ирешә. Аның белән Аурупа илләре кызыксына башлый.

Болгар хан башкалада кәрвансарайлар салдыра, сәүдәгәрләр, илчеләр, сәяхәтчеләр өчен уңай шартлар тудыра.

Бу ханга хатынны кардәш Дунай буе Болгарыннан алып кайталар.

Сәхифә Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН хикәяләвендә бирелә.





Сөекле пәйгамбәребез



БЕРЕНЧЕ МӨСЕЛМАННАР

Һира тавындагы мәгарәдән кайткач, Мөхәммәд хатыны Хәдичәгә үзе белән булган могҗизаны сөйләп бирде.

— Миңа авыр бер вазифа йөкләтелде. Кемне дингә өндим? Миңа кем ышаныр? — дип кайгыга батты.

Хәдичә әйтте:

— Әй, Аллаһның илчесе, хафаланма. Менә мин сиңа ышанамын. Синең пәйгамбәрлегеңне мин кабул иттем! — диде.

Шулай итеп, җир йөзендә беренче мөселман кешесе пәйда булды.

Хәзрәти Мөхәммәд Ислам дине барлыкка килгәнен өч ел буе яшереп тотты. Кешеләрне бик сак кына мөселманлыкка өндәде. Ул иң башта якыннарын, кардәшләрен вә дусларын Исламга әйди башлады. Мөхәммәд пәйгамбәрнең Хәдичә белән намаз укыганын күреп, Гали агасы сорады:

— Бу эшегез нәрсә була? — диде.

Мөхәммәд Исламның вә намазның ни икәнен аңлаткач, Гали дә иман китерде һәм мөселман булды. Аннан соң Зәет бине Харис, аннан соң мөэмин булган кеше хәзрәти Әбу Бәкер...

Шулай итеп, беренче мөэмин мөселманнар утыз кеше булды.

Сәхифәне, төрек язучысы Рәхим ЭР язган «СӘВГЕЛЕ ПӘЙГАМБӘРЕМ» китабыннан файдаланып, БАТУЛЛА әзерләде.

Рәссам Надир АЛЬМЕЕВ

Резеда ВӘЛИЕВА

РӘХӘТ БЕЗНЕҢ АКБАЙГА

Рәхәт безнең Акбайга,
Менә ул бәхет кайда!
Күлмәген юасы юк,
Чалбарын юасы юк,
Үтүкләп куясы юк.
Пычракка керсә дә,
Баткак ерып йөрсә дә,
Ачуланмый берсе дә.
— Чык хәзер үк! — димиләр,
Кагылмыйлар-тимиләр.
Бәйләнми һичберкем дә,
Яши ул үз иркендә.
Рәхәт безнең Акбайга,
Менә ул бәхет кайда!



Булат

Саргылт чәчле,
Зәңгәр күзле,
Алсу йөзле,
Тапкыр сүзле,
Кем икән бу,
Белмисезме?
Эре генә
Атлап йөри,
Сүз сөйләсә,
Җайлап сөйли.
Паровоз да
Була белә,
«Пуф-пуф» итеп
Килә белә.
Дөньяларны
Яңгыратып,
Матур итеп
Көлә белә.
Алсу йөзле,
Зәңгәр күзле
Кем икән бу,
Белмисезме?
Сез белмисез,
Ә мин беләм.
Бу малай
Булат булыр бу,
Танышыгыз
Үзе белән.



Рәссам Равил ХӘСӘНШИН

Лəбиб Лерон

Гөллəр рəхмəте

Мин, сокланып, карап йөрим —
Бүлмə тулы гөллəр белəн:
Сез — ничектер, белмим, ə мин...
Мин аларның телен белəм.

Безнең кебек түгел инде —
Үзлəренчə сөйлəшəлəр...
Елмаешып, бер-берсенə:
— Гөлкəем,— дип эндəшəлəр.

Ал кояшка карыйлар да:
— Бүген көн бик матур! — дилəр...
Алар шулай сөйлəшкəндə
Яктырыплар китə өйлəр.

— Бик сусадык. Безгə тагын
Сулар сипче, Əхмəт! — дилəр...
...Мин су сибəм. Алар миңа
Чəчəк атып:
— Рəхмəт! — дилəр.



Рəсемдəге гөллəрнең кайсылары сезнең өйдə бар? Алоэ белəн каланхоэ гөллəрен тəн тиресе җəрəхəтлəнгəндə кулланалар. Тагын нинди гөллəр дəвалау сəлəтенə ия?

Гөллəр үзлəрен тəрбиялəгəнне ярата. Ə син аларга вакытында су сибəсеңме, туфракларын йомшартасыңмы, ашлыйсыңмы, яфракларындагы тузанны сөртəсеңме?

Рəссам Фəрит МУЛЛАХМƏТ





Бүләк.
Эльвира ГАЙФЕТДИНОВА рәсеме. 12 яшь. Казан.



Натюрморт.
Ләйсән НИЗАМЕТДИНОВА рәсеме. 12 яшь. Казан.



Су буенда.
Рузилә ЗӘЙНУЛЛИНА рәсеме. 8 яшь. Әлки, Карга.



Әтәч белән чебиләр.
Гөлнара ШИҺАПОВА рәсеме. 8 яшь. Казан.



ЛАТИН ЯЗУЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАР ӘЛИФБАСЫ

БАСМА ХӘРЕФЛӘР	ЯЗМА ХӘРЕФЛӘР	КИРИЛЛИЦАДА БИРЕЛЕШЕ	ХӘРЕФЛӘРНЕҢ ИСЕМНӘРЕ	БАСМА ХӘРЕФЛӘР	ЯЗМА ХӘРЕФЛӘР	КИРИЛЛИЦАДА БИРЕЛЕШЕ	ХӘРЕФЛӘРНЕҢ ИСЕМНӘРЕ
A a	*A a*	А а	А	O o	*O o*	О о	О
B в	*B в*	Б б	БЭ	Ɵ ɵ	*Ɵ ɵ*	Ө ө	Ө
Ç ç	*Ç ç*	Җ җ	ҖЭ	P p	*P p*	П п	ПЭ
C c	*C c*	Ч ч	ЧЭ	Q q	*Q q*	Қ қ	ҚА
D d	*D d*	Д д	ДЭ	R r	*R r*	Р р	ЭР
E e	*E e*	Е е	Е/Э/	S s	*S s*	С с	ЭС
Ə ə	*Ə ə*	Ә ә	Ә	Ş ş	*Ş ş*	Ш ш	ША
F f	*F f*	Ф ф	ЭФ	Y y	*Y y*	Ү ү	Ү
G g	*G g*	Г г	ГЭ	T t	*T t*	Т т	ТЭ
Ƣ ƣ	*Ƣ ƣ*	Ғ ғ	ҒЫ	U u	*U u*	У у	У
H h	*H h*	Һ һ	ҺЭ	V v	*V v*	В в	ВЭ
I i	*I i*	И и	И			/КӨНБАТЫШ ЕВРОПА ҺӘМ РУС СҮЗЛӘРЕНДӘ/	
J j	*J j*	Й й	КЫСКА И	X x	*X x*	Х х	ХА
K k	*K k*	К к	КА	Z z	*Z z*	З з	ЗЭ
L l	*L l*	Л л	ЭЛЬ	W w	*W w*	В в	ВЭ
M m	*M m*	М м	ЭМ	Ƶ ƶ	*Ƶ ƶ*	Ж ж	ЖЭ
N n	*N n*	Н н	ЭН	Ь ь	*Ь ь*	Ы ы	Ы
Ꞑ ꞑ	*Ꞑ ꞑ*	Ң ң	ЭҢ	/MƟ'MIN/	'	Э	/МӨЭМИН/

Mm *Mm*



Nn *Nn*

Ꞑꞑ *Ꞑꞑ*



	ꞑ		

Рәссам Айдар ҮТӘГӘН




Дәрдмәнд	*Dərdmənd*
Атам-анам йорты өчен	*Atam-anam jortь ɵcen*
Булса мең җаным фида,	*Bulsa meꞑ çanьm fida,*
Туган-үскән җирем өчен	*Tuƣan-yskən çirem ɵcen*
Соң тамчы каным фида.	*Soꞑ tamcь qanьm fida.*


Сәхифәнең мөгаллиме — филология фәннәре докторы, профессор Вахит ХАКОВ

БОТКАЛЫ


Бертуган Гриммнар әкияте буенча



Булган ди бер кыз.



Беркөнне ул җиләк җыярга урманга баргач, бер карчыкны очраткан.



Карчык аңа:

— Исәнме, кызым, җиләк бирче миңа,— дигән.


Кыз:

— Мә, әбекәй,— дип җиләк биргән.



Карчык җиләкне алып ашаган да кызга әйткән:

— Менә сиңа чүлмәк. Син аңа: «Бер, ике, өч, ботка пеш!» — дигәч, ботка пешә



башлар. «Бер, ике, өч, тукта, җитте ич!» — дигәч, туктар,— дигән. Кыз:


— Рәхмәт, әбекәй,— дип, чүлмәкне алып әнисе янына кайтып киткән.



Әнисе тылсымлы чүлмәккә бик куанган.

ЧҮЛМӘК

Рәссам Әнвәр ЯКУПОВ




Беркөнне кызы каядыр чыгып киткәч, әнисе чүлмәккә:


— Бер, ике, өч, ботка пеш! — дигән. Чүлмәк бик күп ботка пешергән.



Кызның әнисе ботка ашап туйган. Ә чүлмәк ботканы пешерә дә пешерә икән. «Бер, ике, өч, тукта, җитте ич!» дип әйтергә оныткан әни кеше.




Бүлмә ботка белән тулган, ботка ишегалдына да, урамга да ташып чыккан, елга булып ага башлаган.




Кыз бу хәлне күреп өенә йөгергән. Ул керешли үк чүлмәккә:

— Бер, ике, өч, тукта, җитте ич! — дип кычкырган.



Авылдан шәһәргә баручыларга ботканы ашый-ашый юл сарыгга туры килгән.



Кешеләр моңа бер дә зарланмаганнар, чөнки ботка бик тәмле булган.

Раушания Низамова

САРБАЙ ДА ЕЛЫЙ

Хикәя

Иртән елмаеп кояш чыкты. Җылы нурлар Фәниснең йөзен иркәләде. Малай күзләрен ачты. Иң әүвәл ул әнисен, аннан соң шәһәрдән кунакка кайткан Ләйләне һәм аның әнисен күреп алды. «Бүген бакчага бармыйм икән»,— дип уйлап куйды Фәнис.

Ишегалдына ул Ләйлә белән бергә чыкты. Икәүләп Сарбай янына килделәр. Аның йомшак йоннарын сыпырдылар. Ләйләгә сары чебиләрне дә, каз һәм үрдәкләрне дә күрсәтте Фәнис. Әмма Ләйләгә иң ошаганы, әлбәттә, Сарбай булды. Аның белән уйнавы күңеллерәк иде шул!..

Менә Ләйләнең калага китәр көне дә җитте. Ул киткәч, тирә-юнь күңелсезләнеп калгандай булды. Шулчак Фәнискә кемдер елаган кебек тоелды. Ул тавыш килгән тарафка барды. Анда Сарбай сузып-сузып шыңшый иде.

— Сарбай, кил минем янга! — диде Фәнис.

Сарбай Фәнискә борылып та карамады. Ул, Ләйлә киткән якка карап, сулыгып шыңшуын белде. Фәнис Сарбай янына чүмәште. Аның да елыйсы килде. Күзләреннән яшь тамчылары чыкты да Сарбайның йоннарына тамды.

— Елама, Сарбай, елама. Ләйлә тагын кайтыр әле!..— дип маэмайны юатырга тырышты Фәнис.

Сарбай, әлеге сүзләрне аңлагандай, Фәнискә сыенды.



Рәссам Юрий ДЕНИСОВ

КИРЛЕМӘН КИҢӘШЛӘРЕ

Синең маэмаең бар ди. Әгәр шул маэмаең белән башка малайлар вә кызлар алдында мактанасың яки үзеңнең көчле булуыңны күрсәтәсең килсә, болай ит: маэмаеңны иптәшләреңә өстер.

— Өс! Өс! — диген.

Маэмаең үзеңнән акыллырак булса, ул синең фәрманыңны аңламаганга салышыр. Күңелеңне төшермә. Маэмай гына бит әле ул. Үсәр. Эт булыр. Ә хәзергә үзең мүкәлә дә тамаша күрсәткәнеңне карап торган дус-ишләреңә «һау-һау!» диген. Колакка катырак әби-бабайларның артларыннан килеп «һау-һау»ласаң, тагын да шәбрәк булыр. Аларның сискәнеп, егылып китә язуларына игътибар итмә. Син дә алар яшенә җиткән вакытта берәр малай артыңнан килеп «һау»ласа, үзең дә дерт итәр идең, телсез калып, җиргә авар идең...

Шул вакытта сиңа шундый күңелле, рәхәт булыр иде. Әйе бит?!

Әллә киресенчәме?



Салават күпере

5 (27) — 1992

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ СОВЕТ-ФИН УРТАК ПРЕДПРИЯТИЕСЕ «ПОИНТ» ЖУРНАЛЫ

1990 ЕЛНЫҢ МАРТ АЕННАН БИРЛЕ ЧЫГА

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Җаваплы сәркатип
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Айдар УТӘГӘН

Исәп-хисап бүлеге
Розалия ЗАРУБИНА

Тышлыкта Илдар ӘХМӘДИ рәсемнәре

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2.

«Салават күпере» ежемесячный журнал Правления Союза писателей ТССР и Советско-Финского Совместного предприятия «ПОИНТ» (на татарском языке). Основан в 1990 году.

Адрес редакции: 420012, г. Казань, ул. Комлева, 14. Редакция журнала «Салават күпере».

Производствога бирелде 11.05.92 ел. Басарга кул куелды 09.06.92 ел. Кәгазь форматы 84×108 1/16. Басма табак 1,0 (2,1). Нәшер-хисап табагы 3,09. Офсет ысулы белән басыла. Тиражы 10 мең данә. Заказ В-211. Бәясе 10 сум.

Бәясе 10 сум Индекс 73953

